КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 9 декабрь г.Казань № 1207

Балтач муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, «Җирләрне яки җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2004 елның 21 декабрендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Балтач муниципаль районында урнашкан 196,8697 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләрен кушымтада бирелгән исемлек буенча җитештерү эшчәнлеге объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 9 декабрь, 1207 нче
карарына кушымта

Сәнәгать, энергетика, транспорт, элемтә, радиотапшыру, телевидение, информатика җирләре, космос эшчәнлеген тәэмин итү җирләре, оборона, куркынычсызлык җирләре һәм башка махсус билгеләнештәге җирләр категориясенә күчерелә торган җир кишәрлекләре
исемлеге

| Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Мәйданы, гектар | Муниципаль район исеме |
|---|---|---|
| 16:12:080702:75 | 3,1904 | Балтач |
| 16:12:080702:76 | 0,5 | |
| 16:12:080702:79 | 9,1809 | |
| 16:12:080702:80 | 32,7599 | |
| 16:12:080702:81 | 0,722 | |
| 16:12:080702:85 | 0,4178 | |
| 16:12:080702:92 | 143,3642 | |
| 16:12:080702:93 | 1,6292 | |
| 16:12:080702:95 | 0,2906 | |
| 16:12:080702:96 | 0,3878 | |
| 16:12:080702:99 | 0,1909 | |
| 16:12:080702:100 | 0,0959 | |
| 16:12:080702:101 | 0,1346 | |
| 16:12:080702:102 | 0,638 | |
| 16:12:080702:104 | 0,5995 | |
| 16:12:080702:318 | 1,1004 | |
| 16:12:080702:319 | 0,8339 | |
| 16:12:080702:320 | 0,8337 | |
| Барлыгы | 196,8697 | |